**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 4 ноябрь № 841

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 ел, 27 июль, ФЗ-79 нчы Федераль законның 25 статьясындагы 4 өлешнең 1 нче пункты, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге турында» 2017 ел, 6 октябрь, ПУ-889 нчы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\841.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 4 ноябрь, 841 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү
билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүләре шартларында
гамәлгә ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбарасы – эшләр идарәчесе.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбарасы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты идарәсе башлыгы.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты идарәсе башлыгы.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты бүлеге башлыгы.

F:\KARAR\2017\841-1.docx